**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 2 октябрь № 735

г. Казань

2016 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәвалангannan соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга нормативларны, дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативларын;

эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга норматив чыгымнарын;

эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативларын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт учреждениесе (дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга нормативларны, дәвалап бетерү

(тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативларын раслау турында» 2014 ел, 25 сентябрь, 675 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\735.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 02 октябрь, 735 нче карары белән расланды

2016 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативлары

(кеше)

| т/б № | Оешма | Дәвалап бетерүгә (тернәкләндерүгә) җибәрелгән барлык авырулар | Шул исәптән турыдан-туры стационарда дәваланганнан соң | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | кискен миокард инфаркты, стабиль булмаган стенокардия, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларында операцияләр | кискен баш мие кан әйләнеше бозылу | умыртка баганасы үсешендә җитешсезлекләр һәм кимчелекләр булганда ортопедик, травматологик операцияләр, буыннар пластикасы, эндопротезлау һәм реэндопротезлау, кул-аякларны реплантацияләү | йөкле хатыннар авырулары, куркынычлык төркеме | шикәр авыруы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Шифаханә-курорт оешмалары | 4 893 | 2 167 | 368 | 117 | 1 923 | 318 |
| 2. | Дәүләтнеке булган ме- | 657 | - | 603 | 54 | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | дицина оешмалары, шул исәптән: | | | | | | |
| 2.1. | «Сугыш ветераннары өчен госпиталь» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Чаллы шәһәре | 359 | - | 305 | 54 | | |
| 2.2. | «Республика клиник неврология үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 298 | - | 298 | - | - | - |
| | Барысы | 5 550 | 2 167 | 971 | 171 | 1 923 | 318 |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 02 октябрь, 735 нче карары белән расланды

2016 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга норматив чыгымнары

| т/б № | Дәвалап бетерү (тернәкләндерү) профильләре исемлеге | Норматив чыгымнар, койко-көнгә сум |
|---|---|---|
| 1. | Кискен миокард инфаркты, стабиль булмаган стенокардияне турыдан-туры стационарда дәвалаганнан, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларында операцияләрдән соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 141,35 |
| 2. | Кискен баш мие кан әйләнеше бозылуны турыдан-туры стационарда дәвалаганнан соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 135,84 |
| 3. | Умыртка баганасы үсешендә җитешсезлекләр һәм кимчелекләр булганда ортопедик, травматологик операцияләр, буыннар пластикасы, эндопротезлау һәм реэндопротезлау, кул-аякларны реплантацияләүдән соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 121,18 |
| 4. | Куркынычлык төркемендәге йөкле хатыннар авыруларын турыдан-туры стационарда дәвалаганнан соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 119,29 |
| 5. | Шикәр авыруын турыдан-туры стационарда дәвалаганнан соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1 115,62 |

______________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 02 октябрь, 735 нче карары белән расланды

2016 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативлары

| т/б № | Дәвалап бетерү (тернәкләндерү) профильләре исемлеге | Дәвалап бетерүнең (тернәкләндерүнең) дәвамлылыгы, календарь көннәр |
|---|---|---|
| 1. | Кискен миокард инфаркты, стабиль булмаган стенокардияне турыдан-туры стационарда дәвалаганнан, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларында операцияләрдән соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 2. | Кискен баш мие кан әйләнеше бозылуны турыдан-туры стационарда дәвалаганнан соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 3. | Умыртка баганасы үсешендә җитешсезлекләр һәм кимчелекләр булганда ортопедик, травматологик операцияләр, буыннар пластикасы, эндопротезлау һәм реэндопротезлау, кул-аякларны реплантацияләүдән соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 4. | Куркынычлык төркемендәге йөкле хатыннар авыруларын турыдан-туры стационарда дәвалаганнан соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 5. | Шикәр авыруын турыдан-туры стационарда дәвалаганнан соң дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |

___